

ISSN 0868-4545

Укучым!

Хәтерлисең булыр, «Салават күпере»нең алдагы саннарында без сиңа Шигърият дигән Бөек Тылсымны тудыручы Шагыйрьләр, аларның Балачак Иленнән чыгып, ничек итеп зур иҗатчы булганнары турында сөйләгән идек инде. Шагыйрьләр дөньясы, кайберләренең үзләре һәм шигырьләре белән очрашкан идең!

Бүген сине тагын бер кызыклы очрашу көтә. Бездә кунакта Татарстанның халык шагыйре Равил абыегыз ФӘЙЗУЛЛИН.


Д. Бунтуков фоторәсеме.



Cir matur! Cir güzəl! Tik anı
qəderlən, serləren aç qına!
Dərt tulı küzelem barsın da
belergə, kürergə aşkına!

R. F.

Журналыбызның бу санындагы рәсемнәрне рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ ясады.

© "Салават күпере", 2001 ел



Борын-борын заманнан ук...



Борын-борын заманда, әле мин дә тумаганда, әле син дә тумаганда Җир өсте бары тик кара төстә генә булган. Әйе, әйе, болыннар-кырлар, сулар да, хәтта чәчәкләр дә гел кара төстә генә булганнар. Кошлар сайрамаганнар, барысы да козгыннар кебек каркылдашкан гына. Хәтта сыерчыклар да җырлый белмәгән. Кешеләрнең йөзләре дә караңгы булган: берәү дә елмаймаган, көлмәгән. Җыр җырлау, гармун уйнауны бөтенләй белмәгәннәр дә ди хәтта!

Әлбәттә, болай бик күңелсез булган инде.

Бик тә күңелсез генә яшәгән кешеләр.

Менә бер заманны Күк йөзе кинәт яктырып китә дә, алда зур утлы шар пәйда була! Әлеге Шардан бер якты Нур җиргә таба сузыла. Шулчаклы матур, гүзәл була ул Нур: бар кеше дә аңа соклана, һәммәсе дә аны тотып карамакчы була. Әмма әлеге Нур берәүгә дә тоттырырга уйламый. Ул, Җир өсте буйлап әрле-бирле килә-килә, кемнедер эзли, кемнедер тапмакчы була. Һәм таба да: ул уйчан йөзле, бик акыллы бер малай була. Әтисе белән әнисе аңа Шагыйрь дип исем кушкан булалар. Күктән сузылган теге якты Нур Шагыйрь атлы шул малайның учына килә дә куна.

Менә берзаман Шагыйрь малай, Җирдәге иң биек тау өстенә менеп баса да җыр сузып җибәрә. Әлеге җырудан һәм учындагы теге якты Нурдан бар тереклек җанланып китә.





Башлангыч сыйныфларда Равил абыегыз укыган мәктәп. Балык Бистәсе районы, Балтач авылы.

Равил яшь чагында көндәлек алып барган. Шунда ук ул үзенең беренче шигырьләрен дә язып куйган. Ул вакытта Равилгә нибары унбер яшь була.

«Мин Бөек Ватан сугышы вакытында, 1943 нче елның 4 августында тудым. Ерткыч фашистлар армиясе бу вакытта безнең илебезгә, төрле яктан һөҗүм иттеләр. Ниһаять, сугыш бетте. Совет армиясе дошманны җиңде. Безнең Совет халкы сугышта җимерелгән төзелешләрне сугышка кадәргегә караганда да яхшырак итеп эшләде. 1950 елның көзе җитте. Мин беренче класска укырга кердем һәм беренче классны «отлично»га бетереп чыктым.

Шулай ук икенче класста, 1951–52 нче уку елын да «отлично» билгесенә тәмамладым.

Һәм өченче класста укыганда өч фәннән «4»ле билгесе, ә калганнарыннан «5»ле чыкты. Шулай итеп өченче классны «4»ле һәм «5»ле билгеләренә укыдым.

Мин дүртенче класста тагын да тырыштым һәм дүртенче классны «отлично»га тәмамладым. Хәзер бишенче класста укыйм. Быел да «отлично»га укырга тырышам. Мин шагыйрь булырга хыялланам. Һәм шулай итеп мин беренче мәртәбә «Чаңгы шуганда» исемле кечкенә шигырь яздым.»

10 ноябрь 1954 ел. ТАССР
Кызыл Йолдыз районы, Юлсубино (Балтач) авылы.

Әнә шулай, кечкенәдән Шагыйрь булырга теләгән Равилнең хыяллары чыннан да тормышка ашкан! Бүгенге көндә шагыйрь Равил Фәйзуллинның төрле телләрдә чыккан 40 тан артык китабы дөнья буйлап таралган...

Хыял

Җир өстендә ниләр бар?
Әтиләр, әниләр бар.
Шәһәрләр бар, илләр бар.
Урманнар бар, чүлләр бар...

Җир асты да хикмәтле!
Анда хәзинәләр бар.
Алтыннар, көмешләр бар.
Диңгезләр, инешләр бар...

Күк катында ни юк дисез!
Йолдызлар бар, Айлар бар,
яшеннәр бар, карлар бар...

Ә Булатның күңелендә
беләсезме ниләр бар?

Бар аның зур хыялы!
Бәлки андый зур хыялның
юктыр әле булганы!
Аны Җир дә белми әле,
аны Күк тә белми әле,
аны беркем белми әле!..

Бер көн килер, үсеп җитәр –
хыялын ул чынлык итәр!
Ул хыялны Җир дә белер,
эшкә ашуын Күк тә күрер!
Әлегә ул, серен саклап,
нәни генә малай булып,
чирәмлектә аунап йөри.



Максаты булган кеше – көчле кеше.



Sineke – ilneke

Bu tawlar da sineke,
Yılgalar da, tallar da;
qışqı ap-aq burannar da
çəyge alsu taŋnar da...
Kürgən, işetkən, toyğan
həmmə hərsə sineke!

Sin üzeŋme kemneke?
Ə sin tuğan cirneke!
Söyeneçlər kitersəŋ də,
köyeneçlər kitersəŋ də –
barsı ğəziz ilneke.

R. F.



Яхшы сүз

Әйт кенә
тәмле сүз –
иркәләр
күпме күз!

Әйт кенә
яхшы сүз –
һәркемдә
көләч йөз!


Фәйзуллиннар гаиләсе. Сулдан беренче Равил, әнисе Әминә апа, энесе Рөстәм, әтисе Габдрахман ага, сеңлесе Люция, абыйсы Рафаэль. 1953 ел.

Җиләк кайда күп?

Әти, әни, мин – өчәү
йөрибез аланда.
Җыябыз җир җиләк
үләнне аралап.

Җиләк бар аланда!
Яхшылап кара да:
очрый ул алда да,
күренә янда да...

Шулай да җиләкләр
күбрәк табыла
әтием янында,
әнием янында!





Чиләк-чиләк
Эре яңгыр
Явып үтте.
Җиребезне
Саф һавага
Күмеп китте.
Кояш чыкты,
Болытларның
Читен ачып,
Җиде төрле
Буй сөлгесен
Иңгә асып.

Табигать кочагында

Гөл–чәчәкләр өзмәдек без.
Куаклар сындырмадык.
Яшел урман аланында
уйнадык та җырладык!

Кояшка карап елмайдык.
Җилләргә сәлам әйттек.
Һәркем өйгә алып кайтты
бер кочак сәламәтлек!

Балыкта

Кармак, җимнәр алдык та
иртүк киттек балыкка.

Бу кызыл суалчаннарга,
бу ак чебен кортына –
без тиешбез, ким дигәндә,
ярты чиләк тотарга!
Әйтик –
бишләп сыла,
ике-өч чуртан,
җиде бәртәс, бер җәен...
Корбан белән чабак балык
күп булачак, тәгаен.

Бу җепләр дә ярамаса,
бу кармак та тотмаса!
Кайтканда иңнәр салыныр,
балыгың баса-баса.
Тизрәк Ыкка!
Таллыкка!

...Инде кайтып киләбез.
Шырык-шырык көләбез!
Ни өченме көләбез?
Без үзебез беләбез...

Булатка алты чиртте.
Соңгысында чыгарды...
иләмсез зур бер галош!
Ничек, ди, җеп чыдады!

Миңа чиртте зур балык,
тик булмады чыгарып!..
Кармак калды җәеннең
мыегына уралып
Рим ярда күп чуалды.
Төрле урынга салды.


Берсендә чыгарды... минем
кармаклы суалчанны!



Безнең уртак юаныч –
Азат тоткан бер маймыч.
Ята чиләк төбендә,
ун грамм бар кимендә!

...Бүген юл бик уңмады.
Тота идек тотуын –
урыны җай булмады!
Без утырган тугайлыкка
җиле уңай булмады...

Иртәгә тотарга калды
бүгенгесе өчен дә.
Әйтик, берәр чиләк –
унлап сыла,
алты чуртан,
ундүрт бәртәс...



Малай чакта,
бәлки, әлләни
тота алмагандыр,
әмма зур үскәч
байтак эре
балыклар эләк-
терде ул!

Үсү

Эшләр бара кая?
Эшләр бара шуңа –
Алмаз озыная!

Көннәр кыскара,
койма кыскара,
җиңнәр кыскара...
Әнә күктә Ай да
кечерәеп бара.

Ә Алмаз үсә дә үсә!
Һаман озыная!
Менә безнең өйдә
эшләр кая бара!

« Menə bez də üsep citter, Əni!
Qız qazları elekkeçə
Taw başınnan ütə ikən... »

R. F.





Аның Алмаз дигән нәни улы әлегә кырмыскалар күрәштерә.



Менә ул да үсеп җитте,
солдат сафларына китте.



Идел уртасы – гомер уртасы.
Равил абыегыз улы Алмаз, туганы Илдар белән.



Тауга меңгән чак була,



таудан төшкән чак була...



Әле алда тулы гомер!

Өч туган. Сулдан уңга: Равил, Рөстәм, Рафаэль.

60нчы еллар фотолары.

Әй яшь чаклар! Яшь чаклар!
Кесә тулы борчаклар!
Саламнан тәртә каерып
чикерткә җиккән чаклар!

Трамплинда

Урман эченнән чыгып,
трамплин өстенә
тәгәрәп килде дә Ай –
әйтте, ахры, ай-яй!
Уңайсыз төшсәң җиргә,
йә менә алмам күккә, –
сикермим әле тиккә!

Трамплинда мәче!
Ахыры сикермәкче!
Колакларын шомартты,
уңга-сулга күз атты,
мыекларын тырпайтты... –
борылып кире чапты!

Чүлмәкчедән күрмәкче!
Ай сикерә алмаганны,
ничек сикерсен мәче!

...Трамплин өстенә
яшь егетләр килделәр,
Чаңгыларын киделәр.
«Без дә сикерә алмагач,
кем сикерсен?» – диделәр.

Очтылар бер-бер артлы.
Җитезләр! Кош кебекләр!
Кирәк – җирдә, кирәк – күктә
дан ала шәп егетләр!

Дускай! Табигать –үзе бер могҗиза! Аны күреп, аңлап ача гына бел! Без һәр яз саен көтеп алган үлән-чәчәк турында, Шагыйрь абыегыз менә нинди шигырь язган.

Сары чәчәк – тузганак

«Башка сары таҗ
кидем мин! – диде, –
Кояштан да шәп
инде мин!» – диде.

Чыннан да матур!
Чыннан да сары!
Әллә ничә көн
нурланып янды.

Берничә көннән
таҗы урынында
ак бүрек иде.
«Мин айдан да ак
икәнмен!» – диде.

Чыннан да матур!
Чыннан да нәфис!
Торды ул горур
әллә ничә кич.

Ә бер көн баксаң –
сары таҗ кая?
Ак бүрек кая?

...Сузаеп калган
сулган сабагы
җилдә чайкала.



Җәй көне төрле хикмәтле хәлләр гел булып тора инде ул. Менә шуларның берсе.



Булмаганны!..

Тал очыннан былбыл белән рәттән
ишетелә арыслан тавышы.
Умарта оясы ярыгыннан
башын тыккан бер тавис кошы.

Авыл читендәге Кече күлдән
ак акула бер үрдәк тоткан.
Ярый әле Салих бабай күреп,
бармак янап аны куркыткан!

«Салават күпере»
булса гел янында –
Аңларсың Шагыйрьнең
уен да,
җырын да,
җанын да !



Яңгыр

Күк гөмбәзе тишелгән!
Ага бөтен төшеннән.
Күк белән Җир – бер тоташ.
Яше-карты чайкый баш:
«Ай-һай яңгыр бу, яңгыр!»

Ә яңгыр малайлары –
кирәклеме димиләр,
кирәксезме димиләр –
сикерешеп төшәләр дә
бииләр дә бииләр!

Бииләр күлләвектә,
бииләр гөрләвектә,
тояк эзләрендә дә,
чәчәк күзләрендә дә...

Күпне күргән кешеләр,
туктап калып эшеннән:
«Артыкка китте! – диләр, –
җиргә дым җитте!» – диләр.

...Күкнең төбе тишелгән!
Болыт тавы ишелгән!
Коела гына тамчылар
теләсә кай төшеннән!

Җирдә рәхәт, дип микән,
без ирektә, дип микән,
бииләр дә
бииләр!



Онытма син!

Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәнеңне онытма син!

Бел син ерак бабайларның
ничек итеп көн иткәнен,
ни иккәнен, ни чиккәнен,
нинди уйлар, нинди моңнар
безгә калдырып киткәнен.
Исеңдә тот, аларның син
сугышларда кан түккәнен,
Туган җирнең иреге өчен
зинданнарда интеккәнен...


Һәр карыш җир сугарылган
шәһит җаннар каннарында.
Үткән яулар шәүләсе бар
Туган якның таңнарында.

Һәр нигезнең, һәр авылның,
Һәр каланың үткәне бар...
Гыйбрәт алырлык мирасның
калганы бар, киткәне бар...

Горур сүз әйт, сорасалар:
Ни кавемнән? Нинди җирдән?
Киләчәккә аек карар
үз тарихын анык белгән!

Хәтерләүдән курыкма син!
Ил үткәнен онытма син!





Юлда

Бер таяк.
Ике аяк.
Өч авыл.
Ун чакрым.
Егерме төш.
Утыз ике теш.
Кырык уй.
Йөз исәп.
Мең адым...

Уф, ардым!

Артымда –
биш чакрым.
Өч күпер.
Ике авыл.
Бер күләгә.
Ярты юл.

Алдымда –
биш чакрым.
Өч үзән.
Ике үр.
Бер авыл.
Ярты юл...

Һәм тагын –
бер Кояш.
Бер әби.
Бер бабай.
Аларга
кунакка
баручы
мин – малай.









Кәгазь

Без укый торган китаплар,
без яза торган дәфтәрләр,
без карый торган альбомнар...
башта – агач булганнар.
Яфрак ярып, җилдә шаулап,
Җирдә басып торганнар.
Аннан аларны екканнар,
чапканнар һәм кискәннәр...
Машиналардан үткәреп,
юка кәгазь иткәннәр.
Алдымда — чиста, ак кәгазь
Нинди агачтан икән?
Каеннанмы, нараттанмы,
әллә усактан микән?
Аның урынына яңаны
кемдер утырткан микән?..
...Уйлап тордым да, ясадым
кәгазьгә бер имәнне.
Ясадым мин имәннең
шәбен – менә дигәнен!
Очы күккә тигәнен
Мәңге үсеп торырлыкны.
Кош оя корырлыкны.
Күргән кеше шатлансын.
Кәгазьдә генә булса да,
тагын бер агач артсын!

Cırlarda – Il ğame

R.F.



Дусларны чәчеп җыям...



Шагыйрь **Равил Фәйзуллин**, композитор **Нәҗип Җиһанов**, режиссер **Шириял Сарымсаков**. 1980 ел.



Сулдан уңга – утырганнар: композитор **Сара Садыйкова**, шагыйрь **Сибгат Хәким**; басып торалар – язучы **Гариф Ахунов**, җырчы **Вафирә Гыйззәтуллина**, шагыйрь **Равил Фәйзуллин**. 1981 ел.



Равил Фәйзуллин бөек сынчы **Бакый Урманче** белән. 1985 ел.



Шигърият дуслыгы – халыклар дуслыгы.
Сулдан уңга – балкар шагыйре **Кайсын Кулиев**, **Равил Фәйзуллин**, **Хәсән Туфан**, рус шагыйре **Сергей Орлов**. 1976 ел.



Илләр, җирләр гизүчегә

Йөр, күр, бел син күп җирләрне,
күп илләрне.
Сау җаныңа һәрбер тараф якын булсын.
Күзең күргән һәр матурдан, һәр яңадан
Күңелеңә хикмәт кунсын, акыл кунсын.


Дөнья зур ул: шәп балкышлар бик күп очрар.
(Егетлегең сыналыр да инде шунда!)
Һич күләгә төшермә син җаныңдагы
Туган илең, туган җирең яктысына!

Файдалыны – күргән җирләр биргәнчә ал.
Тик үзең дә алган төшкә нур чәчә ал!





Шотландия. 1997 ел.



Египет. 1996 ел.



Германия. 1995 ел.



Англия. 1997 ел.



Мальта. 1997 ел.



Пакистан. 1998 ел.

Равил абыегыз – күп илләр, күп җирләр күргән Шагыйрь Ул!

Яңа Гасыр –
Синә, Газизем!



Газиз Улым!
Газиз Җирем!
Газиз Ватаным!

Җир йөзендә барлык аналарны
Сөендереп, шатландырып атсын
Туган Илнең һәрбер ал таңы.



Салават күпере

7(137) — 2001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАТБУГАТ, ТЕЛЕРАДИОТАПШЫРУЛАР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ МАССАКУЛӘМ КОММУНИКАЦИЯ ЧАРАЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ 1990 елның март аеннан бирле чыга.

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства по делам печати, телерадиовещания и средств массовых коммуникаций РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке. Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Лилия ЗОЛОНДИНОВА рәсемләре.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тәсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 4.7.2001 ел.
Басарга кул куелды 4.7.2001 ел.
Кәгазь форматы 84x108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 13369 дана. Заказ А-273.
Бәясе килешү буенча.

POINT®

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Равил ФӘЙЗУЛЛИН

Бердәнбер

Туган ил – бердәнбер.
Әниең – бердәнбер.
Әтиең – бердәнбер.
Син үзең – бердәнбер.

Калырсың беркөнне
дөнья каршында
бергә – бер!

Хәвефләр алдында –
бергә – бер.

Сынаулар алдында –
бергә – бер.

Бурычлар алдында –
бергә – бер.

Намусың алдында –
бергә – бер...

Башкарган эшеңә
ни дияр –
Ватаның,
Әтиең,
Әниең?

Аларның хөкеме –
иң гадел, бердәнбер!

Әтиең, Әниең
куанып туялмас
Әйтсәләр:
«Ул егет – Илдә бер!
Илдә бер!»

